**Казан шәһәр Думасының 2024 елның 28 августындагы**
**4-32 номерлы карары**

**Казан шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә территориядән фактта файдалануның территориаль зонасы (Ф) (2 номерлы контур) чикләрен үзгәртү өлешендә үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 33 статьясы, Казан шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең 20 статьясы нигезендә, Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 12 апрелендәге 1549 номерлы «Казан шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә территориядән фактта файдалануның территориаль зонасы (Ф) (2 номерлы контур) чикләрен үзгәртү өлешендә үзгәрешләр кертү турында Казан шәһәр Думасы карары проектын әзерләү хакында» карарын, 2023 елның 13 октябрендәге 3067 номерлы «Каенлы» территориясен планлаштыру проектын раслау турында» карарын һәм 2024 елның 4 июленнән 2024 елның 18 июленә кадәр уздырылган иҗтимагый фикер алышуларның нәтиҗәләрен исәпкә алып, Казан шәһәр Думасы **карар чыгарды**:

1. Казан шәһәр Думасының 2021 елның 16 августындагы 5-8 номерлы карары белән расланган Казан шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә (алга таба – Кагыйдәләр) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. шәһәр төзелешен зоналаштыру (территориаль зоналар) картасында әлеге карарның 1 номерлы кушымтасына туры китереп, чикләрен үзгәртергә; 16:50:171402:225 кадастр номеры 11892 кв.м мәйданлы, 16:50:171402:229 кадастр номерлы 106987 кв.м мәйданлы, 16:50:171402:217 кадастр номерлы 12528 кв.м мәйданлы җир кишәрлекләренә карата территориаль зона – катнаш торак һәм иҗтимагый төзелеш зонасын (ОЖ) (69 номерлы контур) һәм 16:50:171402:228 кадастр номерлы 8429 кв.м мәйданлы, 16:50:171402:227 кадастр номерлы 29505 кв.м мәйданлы җир кишәрлекләренә карата территориаль зона – мәгариф объектларын урнаштыру зонасын (О2) (3 номерлы контур, 17 номерлы контур) билгеләп, территориядән фактта файдалану зонасының (Ф) (2 номерлы контур) территориаль зонасы чикләрен үзгәртергә;

1.2. әлеге карарның 1.1 пунктчасында күрсәтелгән территориаль зоналарның үзгәрә торган чикләрен Кагыйдәләр составында түбәндәге шәһәр төзелеше зоналаштыру карталарында күрсәтергә:

- шәһәр төзелешен зоналаштыру (территориаль зоналар) картасы;

- территориаль зоналарның ярдәмче зоналары: урам-юл челтәре, табигый-рекреацион комплекс, махсус билгеләнештәге яшелләндерү, яр буе территорияләре күрсәтелгән шәһәр төзелешен зоналаштыру картасы;

- территориаль зоналарның ярдәмче зоналары: территорияләрдән, шәһәр төзелеше әһәмиятле территорияләрдән файдалануның югары интенсивлыгы күрсәтелгән шәһәр төзелешен зоналаштыру картасы;

- территориаль зоналарның ярдәмче зоналары: тарихи җирлекнең ярдәмче зонасы күрсәтелгән шәһәр төзелешен зоналаштыру картасы;

- чикләрендә территорияләрне комплекслы үстерү каралган территорияләр картасы;

1.3. Кагыйдәләргә 1 номерлы кушымтага әлеге карарга 2 номерлы кушымта нигезендә (хезмәттә файдалану өчен) территориаль зоналар чикләре урнашу урынының график тасвирламасын өстәргә (китерелми);


1.4. Кагыйдәләргә 2 номерлы кушымтаны әлеге карарга 3 номерлы кушымта нигезендә территориаль зоналар чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге (хезмәттә файдалану өчен) белән тулыландырырга (китерелми).

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында бастырып чыгарырга (www.docskzn.ru).

**Шәһәр Мэры** **И.Р.Метшин**

Казан шәһәр Думасының 2024
елның 28 августындагы 4-32
номерлы карарына 1 номерлы
кушымта

**Казан шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре составындагы шәһәр төзелешен зоналаштыру (территориаль зоналар) картасы фрагменты**




**Шартлы билгеләр**

**ОЖ - 69**

Территориаль зона контурының тәртип номеры

Территориаль зона индексы

**Территориаль зона**

| **Төс** | **Индекс** | **Территориаль зона төре исеме** |
|---|---|---|
| | ОЖ | Катнаш торак һәм иҗтимагый төзелеш зонасы |
| | О2 | Мәгариф объектларын урнаштыру зонасы |
| | Ф | Территориядән фактта файдалану зонасы |
| | | Казан шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре составындагы шәһәр төзелешен зоналаштыру (территориаль зоналар) картасы фрагменты чиге |

**Башлык урынбасары** **Е.А.Лодвигова**